**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

__02.10.2025____ №__820______

**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының "муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 25.07.2019 ел, № 548 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27.07.2010 елгы 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 25.07.2019 ел, № 548 карары белән расланган Гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1) 2.9 бүлегенең 2 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, моңа мондый гариза белән шушы ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәттә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган граждан мөрәҗәгать иткән очраклар керми. федераль законнар нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алу хокукына ия булган, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә йә Җир Кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык кишәрлеге булса), шулай ук гражданнар бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә үз ихтыяҗлары өчен урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);

2) 2.9 бүлегенең 2 пунктындагы 16 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

16) коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтенә җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән күләмнән артып китә;

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**